ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**07.06.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1696**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 3 декабрендәге 2630 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә - педагогик хезмәткәрләргә, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән, ай саен өстәмә түләүне стимуллаштыру тәртибенә үзгәреш кертү турында (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 маендагы 1127 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләре белән)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимул өстәмәләре билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022елның 15 ноябрендәге номерлы карары нигезендә. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 3 декабрендәге 2630 номерлы карары белән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 маендагы 1127 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләре белән, расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә - педагогик хезмәткәрләргә, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән, ай саен өстәмә түләүне стимуллаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 14 нче пунктта:

өченче абзацта «1 111 сум» сүзләрен «2 510 сум» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «1 111 сум» сүзләрен «2 510 сум» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 15 нче пунктта:

өченче абзацта «1 111 сум» сүзләрен «2 510 сум» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «1 111 сум» сүзләрен «2 510 сум» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2023 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр буенча начальнигына «Интернет» челтәрендәге Татарстан Республикасының

(http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru.) рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгына йөкләргә.

Җитәкче вазыфаларын башкаручы А.В. Старостин